КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 409

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, төзү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 928 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, төзү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, төзү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 928 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 май, 336 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, төзү һәм алардан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Парковкалар (парковка урыннары) оештыру кирәклеге Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль юлларының техник торышын бәяләү тәртибе турында» 2020 елның 7 августындагы 288 номерлы боерыгы белән расланган Тәртиптә автомобиль юлларының техник торышын бәяләгәндә билгеләнә.»;

2.7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Автомобиль юлларында урнашкан парковкаларның параметрлары 2.05.02-85 нче төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре таләпләреннән чыгып билгеләнә һәм «Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары» дигән Р 52289-2019 нчы дәүләт стандарты (ГОСТ) нигезендә мәҗбүри рәвештә тәртипкә китерелергә тиеш. Юл билгеләре, юл сызыклары, светофорлар, юл киртәләре һәм юнәлеш бирә торган җайланмаларны куллану кагыйдәләре» һәм «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Тәртипкә китерү элементлары. Гомуми таләпләр» дигән Р 52766-2007 нче дәүләт стандарты (ГОСТ)»;

2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Барлык парковкаларда урыннарның (әмма бер урыннан ким түгел) кимендә 10 проценты I, II төркем инвалидлар тарафыннан идарә ителә торган транспорт чараларын  һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны йөртә торган транспорт чараларын бушлай куеп тору өчен, шулай ук III төркем инвалидлары арасыннан түбәндәге гражданнарга бирелә:

а) чагылыш дәрәҗәсе (1, 2 яки 3 дәрәҗә) төрле булган мөстәкыйль хәрәкәт итүгә сәләте чикле гражданнар;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «III төркем инвалидлары арасыннан булган гражданнарга «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 15 статьясындагы тугызынчы өлеше нормалары кагылу тәртибе турында» 2020 елның 10 февралендәге 115 номерлы карары үз көченә кергәнгә кадәр индивидуаль файдалану өчен федераль медицина-социаль экспертизасы учреждениесендә «Инвалид» тану билгесен алган һәм транспорт чараларын вакытлыча куеп тору урыннарын түләүсез файдалану хокукын файдаланган гражданнар.

Әлеге транспорт чараларында «Инвалид» тану билгесе куелырга тиеш, һәм бу транспорт чаралары турындагы мәгълүмат инвалидларның федераль реестрына кертелергә тиеш.

Бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакытлыча куеп тору урыннарына башка транспорт (Россия Федерациясенең Юл хәрәкәте кагыйдәләрендә каралган очрактан тыш) куелмаска тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин